| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 16.12.2024 | г.Казань | № 512-69/тэ-2024 |

«Тәтеш җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 04.12.2020 ел, №341-51/тэ-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2025 ел өчен төзәтү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 16.12.2024 ел, №33-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2025 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2025 елга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Тәтеш җылылык челтәрләре предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү турында» 04.12.2020 ел, №341-51/тэ-2020 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 12.11.2021 ел, № 256-43/тэ-2021, 16.11.2022 ел, № 484-73/тэ-2022, 08.12.2023 ел, № 452-40/тэ-2023 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән билгеләнгән тарифларны 2025 ел өчен төгәлләштереп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бирергә (кушымтада).

2. Әлеге карарның 1 пунктында төгәлләштерелгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 04.12.2020 ел, №341-51/тэ-2020 карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2024 № 512-69/тэ-2024 карары редакциясендә)

## «Тәтеш җылылык челтәрләре предприятиесе» ААҖ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | басым астында сайланма пар | | | | кискен һәм редукция ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Тәтеш муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Тәтеш җылылык челтәрләре предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1 872,51 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1 874,66 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1 874,66 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1 959,85 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 2 044,06 <*> | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 2 044,06 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 | 2 289,35 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кадәр | | | | | | |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 2 289,35 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 2 628,45 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән) <**> | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 2 247,01 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 2 249,59 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 2 249,59 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 2 351,82 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 2 452,87 <*> | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 2 452,87 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 2 747,22 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 2 747,22 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 3 154,14 | - | - | - | - | - |

<*> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14

ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге